| МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | г. Казань | **БОЕРЫК** |
| 02.07.2019 | | № 253 |

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы каршындагы журналистларны аккредитацияләү Кагыйдәләрен раслау турында**

1991 ел 27 нче декабрь №2124-1 Россия Федерациясе Законының 48 нче «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» статьясы нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы каршындагы теркәлгән журналистларны аккредитацияләү Кагыйдәләрен расларга.

2. Министрлыкның мәгълүмат бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы ГТХМ рәсми Интернет-сайтында урнаштырырга.

3. Биредәге Боерыкны үтәү контролен үземә калдырам.

Министр вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Т.В. Кәримуллин

02.07.2019 № 253
Татарстан Республикасы
ГТХМ боерыгы белән
расланганнар

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы каршындагы журналистларны аккредитацияләү Кагыйдәләре**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге кагыйдәләр 1991 ел 27 нче декабрь № 2124-1 Россия Федерациясе Законының 48 нче «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы (алда - Татарстан Республикасы ГТХМ) каршындагы массакүләм мәгълүмат чараларын аккредитацияләү (алда – аккредитация) тәртибен регламентлаштыралар.

1.2. Аккредитация вакыты чикләнмичә башкарыла. Массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе теләге буенча аккредитация конкрет редакция биремен үтәү өчен кирәкле срокта (вакытлы аккредитация) гамәлгә ашырылырга мөмкин.

II. Аккредитация алу хокукы

2.1. Аккредитациягә милек формасына һәм гамәлгә куючылар составына, шул исәптән чит ил массакүләм мәгълүмат чараларына бәйсез рәвештә массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре ия. Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен аны Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршындагы аккредитацияләүне раслау зарур.

III. Аккредитация тәртибе

3.1. Аккредитациягә гариза Татарстан Республикасы ГТХМна әлеге гаризаның фактын, датасын һәм алу вакытын расларга мөмкинлек бирүче теләсә нинди ысул белән массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе җитәкчесе имзасы белән бирелә.

3.2. Гаризада журналистның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), аның вазыйфасы, эш һәм кесә телефоннары, электрон почта адресы, массакүләм мәгълүмат чараларының тулы исеме, массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү турында таныклык датасы һәм номеры күрсәтелә.

Вакытлыча аккредитация алуга гаризада шулай ук редакция йөкләмәсе һәм аның үтәлеше чоры күрсәтелә.

Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитацияне раслый торган документларның күчермәләре куела.

3.3. Әлеге Кагыйдәләрнең 3.2 пункты таләпләренә туры килми торган гаризалар каралмый.

3.4. Аккредитация турында (аккредитация алудан баш тарту турында) карар Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министры (аның вазыйфаларын башкаручы) (алгда – министр) тарафыннан гариза кергән көннән алып ике эш көненнән соңга калмыйча кабул ителә. Мондый карар тиешле министр боерыгы чыккан көннән соң икенче эш көненнән соңга калмыйча, редакциягә гариза җибәргән массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясенә аны алу фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирүче теләсә нинди ысул белән җиткерелә.

3.5. Массакүләм мәгълүмат чаралары махсус характерда (реклама тарату, эротик басмалар) булса, аккредитациядә баш тарта.

3.6. Аккредитация турындагы гаризаны карау, министрның аккредитация (аккредитацияләүдән баш тарту) турында боерыгы проектын әзерләү, шулай ук массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә кабул ителгән карар турында хәбәр итү Татарстан Республикасы ГТХМның массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге тарафыннан әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

## IV. Аккредитацияләнгән журналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналистлар түбәндәгеләргә хокуклы:

чарада булу;

Татарстан Республикасы ГТХМ карамагында булган чара турында рәсми документларның күчермәләрен алырга (көн тәртибе, матбугат релизлары, мәгълүмати-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материаллар);

бастыру өчен билгеләнгән мәгълүмат-белешмә материаллар белән танышу;

Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокуклар.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистлар түбәндәгеләргә бурычлы:

массакүләм мәгълүмат чаралары өчен махсус оештырылмаган очракта, чараның регламентын үтәргә һәм аның барышына катышмаска;

чарада катнашучыларның эшчәнлегенә комачауламаска;

Татарстан Республикасы ГТХМ тәкъдим иткән матбугат релизлары, мәгълүмати-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материаллар кулланганда (эфирда эшләгәндә) мәгълүмат чыганагына сылтама ясарга;

үз һөнәри эшчәнлеген тормышка ашырганда Татарстан Республикасы ГТХМ эшчәнлеге турында гамьсез мәгълүматлар таратмаска.